| | |
|---|---|
| СОВЕТ ТОЙГУЗИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МЕНДЕЛЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТОЙГУҖА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

Р Е Ш Е Н И Е　　　　　　　　　　　　К А Р А Р

21.12. 2023 ел　　　　　　　　　　　　№103

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Тойгуҗа авыл җирлегендә
муниципаль хезмәт турында
нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 10 статьясына үзгәрешләр кертү хакында" 2023 елның 2 ноябрендәге 99-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Менделеевск муниципаль районы Тойгуҗа авыл җирлеге Советы КАРАР КЫЛДЫ

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Тойгуҗа авыл җирлеге Советының 2023 елның 16 гыйнварендагы 51 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Тойгуҗа авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 2.5 статьяның 20 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«20. Муниципаль хезмәткәргә класслы чин бирү турындагы карар, әлеге статьяның 13 өлешендә күрсәтелгән очраклардан тыш, чин бирүгә вәкаләтле җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затына барлык кирәкле документлары булган класслы чин бирү турында тәкъдим кертелгән көннән алып бер айдан да соңга калмыйча кабул ителергә тиеш.»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында http://mendeleevsk.tatarstan.ru " Тойгуҗа авыл җирлеге" бүлегендә урнаштырырга

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Тойгуҗа авыл җирлеге Советы рәисе　　　　　　　　Р.А.Сафин